**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

15 июль 2024 ел. № 237

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставы нигезендә, 2024 елның 13 июнендә узган тыңлаулар беркетмәләрен һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының 04.10.2021 № 71 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Кулле-киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.2 Кагыйдәләрнең график һәм текст материалларының эчтәлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- «IV-V класслы хәвефлелектәге җитештерү һәм склад объектлары зонасы (ПЗ) №5-7» территориаль зонасы чикләрен билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенә «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы карарны Федераль дәүләт мәгълүмат системасының (https://fgistp.economy.gov.ru) рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм ТР Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (www.atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы
Әтнә район Советы рәисе — Г.Г.Хәкимов